ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ

# КАРАР

" 27 " март 2026 ел Боерган авылы № 6/4

**“2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап“**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башлыгы Минакова Гөлүзә Гаязовнаның «2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 12389,90 мең сум, чыгымнар буенча 10479,41 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
- 2025 ел өчен Боерган авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Боерган авыл җирлеге
Совет рәисе Г.Г.Минакова